СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
**21.03.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 463**

Зеленодольск муниципаль районы Советының «Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге тарафыннан тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча ревизия комиссияләре вәкаләтләрен кабул итү турында» 2015 елның 2 февралендәге 486 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 29 декабрендәге 164 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

«Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисе Кадыйрова С.В. мәгълүматларын тыңлап фикер алышканнан соң, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының «Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге тарафыннан тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча ревизия комиссияләре вәкаләтләрен кабул итү турында» 2015 елның 2 февралендәге 486 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2016 елның 29 декабрендәге 164 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендә «ревизия комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Карар преамбуласында «ревизия комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. Карарның 1 пунктында «ревизия комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат (https://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми (https://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**